## *“Синең хөрмәтле  мөгаллимнәрең, туган мәктәбем!”*

### **Зөфәр Ярулловиич Сәгыйтов – күпьяклы шәхес**



З.Я. Сәгыйтов Чаллыдан ерак түгел генә урнашкан Биклән авылында1929 елның 22 ав-густында  туа. Хезмәт юлын  Ватан сугышы елларында 14 яшендә Чаллыда “Штурм” кинотеатрында киномеханик булып башлый. Чаллы, Сарман һәм башка авылларда кино күрсәтеп йөри. Атларның күбесе фронтка алынганлыктан, үгезләр җигеп йөрергә дә туры килә аңа. Аннары ул Красноярск өлкәсе Ачинск шәһәрендәге авиация училищесына укырга керә. Аны  “бик яхшы” билгеләренә генә тәмам-лый. Украинада очкычлар төзү заводында авиация механигы  булып эшләгәндә,  берничә яңалык кертә.

Туган якларына өйләнеп кайткач, егет Алабуга культура - агарту училищесын, аннары Казан педагогия  институтының музыка факультетын тәмамлый.




Зөфәр Ярулловичны шәһәрдә укытучы һәм композитор буларак яхшы беләләр.

Ул  20 елдан артык  М. Вахитов исемендәге урта мәктәптә балалар укы-та. Музыкадан тыш автодело, электротехника дәресләрен алып бара.






Моннан тыш ул күп төрле һөнәрләр белән мавыга. Зөфәр Яруллович – күпьяклы шәхес. Мәктәптә эшләгәндә ватык машиналар калдыгыннан ГАЗ машинасы җыя. Укучылар шул машинада өйрәнеп,өченче класслы машина йөртүче таныклыгы алалар.



Укытучы кабиналы,чаңгылы аэрочана ясап, туган авылы Бикләнгә кайтып йөри. Зөфәр Яруллович киемнәр тегә, фотография белән мавыга, бик матур итеп рәсемнәр ясый, сәгатьләр төзәтә, хәтта мич тә чыгара.

Тик иң төп һөнәре музыка белән бәйлеаның. Нинди генә музыка корал-ларында уйнамый Зөфәр Яруллович: аккардеонда, баянда, төрле-төрле гар-муннарда, фортепионода, курайда!


Мно-го пе-сен слы-хал я


Мно-го пе-


-сен слы-хал я





Укытучылык эшчәнлеге белән бергә Зөфәр Сәгыйтов көйләр яза, укучылар белән бергә концертлар куя. Педагог оештырган дүрт тавышка җырлаучы данлыклы 2 мәктәп хоры үзешчән сәнгать смотрларында һәрвакыт беренче урыннар ала.



ЗөфәрЯруллович моннан тыш мәктәптә һәм шәһәрдә вокаль ансамбльләр оештыра. Энергетик” мәдәният сараенда “Ләйсән” ансамбленә җитәкчелек итә.





Республика телевидение һәм радиосы аша ансамбль чыгышларын тамашачылар яратып тыңлыйлар. Язмалар бүгенге көндә дә еш башкарыла.





ТКУ һәм ПТУ№ 8 студентлары катнашында маэстро тарафыннан төзелгән хорлар шәһәрдә үткәрелгән бәйрәмнәрдә актив катнаша.



Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан уздырылган Бөтенсоюз сәнгать иҗаты конкурсында хор, Зөфәр Сәгыйтовның үзе язган “Мәңгелек ут”, “Без тынычлык сагында” җырларын башкарып, беренче урынга лаек була.



2 мәктәптә башланган иҗат активлыгын дәвам итеп, Зөфәр Сәгыйтовтанылган татар шагыйрьләре һәм үз сүзләренә төрле жанрдагы 40 тан артык җыр иҗат итте.




Композиторлык эшчәнлеге өчен Сәгыйтов З.Я.1985 елда СССР Композиторлар союзының Алтын медаленә лаек була.



"Мәңгелек ут", "КамАЗ даннары", "Минем бабай - фронтовик", "Штурмовик турында баллада", "Җырлыйк, дуслар" кебек җырларны татар һәм рус телләрендә дә башкаралар.

Чаллы турында иң беренче җырны Зөфәр Яруллович иҗат итә. "Туган шәһәрем Чаллы" җыры Һаҗар Гәрәева сүзләренә 1977 елда ук языла. Ул шәһәр мэры В.Г. Шәйхразиев тарафыннан Диплом белән бүләкләнә, шәһәр турындагы төрле дискаларга кертелә.




Зөфәр Сәгыйтов - камера оркестры өчен иҗат ителгән күпсанлы инстру-менталь әсәрләр авторы. Аның әсәрләре республика һәм шәһәр күләмендә оештырылган тантаналарда - мәйданнарда, стадионнарда яңгырый. “Та-тарстаным” һәм “Минем бабай- фронтовик” җырларына клип төшерелде, һәм алар “ТНВ”, “ЧелныТВ” каналларыннан күрсәтелә. Зөфәр Ярулловичның бик күп җырлары татар композиторлары әсәрләре тупланган җыентыкларда 1968 - 1975 елларда басылып чыкты, шәһәр газеталарында даими дөнья күрде.

Зөфәр Ярулловичь Сәгыйтовның күпкырлы иҗат эшчәнлеге республика һәм шәһәр язучылары һәм журналистлары игътибарын үзенә тарта. Аның турында “Ватаным Татарстан”, “Советская Татария”, “Шәһри Чаллы”, “Нур”, “Көмеш кыңгырау” һ.б. газеталарда төрле елларда мәкалә һәм очерклар басылып чыга ( Кушымта №1-29)

Сәгыйтовлар гаиләсе - музыкаль гаилә. Тормыш иптәше Людмила Михайловна да музыка мәктәбендә укыта, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. Кызы Лира, консерватория тәмамлап, татар дәүләт фольклор ансамблендә эшли: бик матур җырлый, скрипкада уйный.

Талантлы остаз бүгенге көндә дә М. Вахитов исемендәге 2 гимназиядә укучыларга патриотик тәрбия бирүдә һәм музыкаль мирасны таратуда зур хезмәт куя. Без сезнең белән горурланабыз, Сәгыйть Ярулловичь! Озын-озак сәламәт яшә, хөрмәтле ветеран!

*Гайнетдинова Илүзә, 2 гимназиянең 8в классы укучысы.*

**Кушымта №1**

ФК — Зеркало

# “ТРЕПЕЩЕТ ПЕСНЯ В МОЕЙ ГРУДИ“




*Фото ШАКИРЗЯНОВА*

Если бы мне предложили снять фильм о жизни духовной элиты, то я, не задумываясь, остановила бы свой выбор на Зуфаре Сагитове. И не только потому, что преклоняюсь перед этим музыкантом и композитором, чей талант сравним с даром селекционера, выводящего из сорняковых сортов совершеннейший по красоте цветок. Так и Зуфар из какофонии, сопровождающей наше бытие, улавливает чистые, прозрачные, как глоток родниковой воды, звуки и преобразует их в мотивы. В его песнях затасканное, заболтанное, захватанное неумелыми руками слово “фольклор“ приобретает первозданную значимость. А еще Зуфар Яруллович обладает не менее редким даром наделять духовностью даже неодушевленные предметы, которые его окружают в быту. Это тот случай, когда вещи говорят о хозяине больше, чем слова.

Яблоневый сад, добротный деревянный дом, а в доме - старинные комнатный орган, граммофон, часы с боем...

Эти драгоценные реликвии достались Зуфару Ярулловичу в наследство от его деда. По деревенским меркам, тот был большой чудак. Неугомонный нрав долго носил его по чужбине. Искал он счастья и на золотых приисках. “Намыл“ там немало деньжат. Но опять-таки, как потом говаривали деревенские, шайтан его попутал. Потратил сбережения на покупку немецкого органа, французских часов и граммофона. Когда привез их домой, на заморские дива сбежалась поглазеть вся деревня. Вот разговоров-то было! Но бабай Зуфара вообще был по натуре поперечный человек. Имел свои представления о жизни и смело претворял их в жизнь. Так он стал автором и другой “реформы“: на глазах у честной публики выволок из дома святая святых татарских обывателей - саке - деревянный настил, выполнявший функцию лежака, и внес в горницу никелированные кровати...

Не знаю, как для вас, а для меня жизнь этого человека - лишнее доказательство того, что интеллигентность - внутреннее состояние, образ жизни, а не довесок к диплому или социальный статус. Это еще раз доказывает, что тяга к музыке, тонкое чутье звуковой гармонии - удел не только рафинированных эстетов, получивших салонное образование. “Музыкальный вирус“ порой прописывается в генетическом коде и крестьянина, как это и случилось с Сагитовыми...

Вихрастая макушка Зуфара едва выглядывала из-за водруженной на его колени гармони, но меха ее уже выдували ладные мелодии. Но никто, глядя на него, не всплескивал руками: “Ах, смышленый какой!“. Все дети Сагитовых осваивали эту премудрость наравне с другими житейскими хитростями. Так, по наитию, без освоения нотной грамоты, Зуфар пришел к музыке. Потом гармонь частенько ему помогала в армии разгонять тоску по родине. А на музыкальном факультете педагогического института Зуфар “брал гармонь шальную и растягивал лады“ уже не только в порыве душевного подъема.

Затем была работа в школе N2 Набережных Челнов. Не надо сильно напрягаться, чтобы вспомнить, какое место отводила тогда система усредненного образования урокам музыки. Это было что-то вроде узаконенного расслабона между геометрией и литературой. Но Зуфар Яруллович не собирался мириться со второсортностью своего предмета. Но боролся он (если можно так сказать) не методом агитации, а методом внушения: виртуозно играл на гармони, разучивал с детьми песни, стараясь довести до них всю палитру красок, сочность языка и глубину образов татарских напевов. И, надо сказать, семена падали на благодатную почву. Многие из учеников Зуфара Ярулловича хотя и не стали великими певцами, но зато научились слушать и понимать музыку, песни. И это уже очень много. И еще: в галерее памяти, согласитесь, лица школьных учителей занимают не последние места. Но не всех их мы вспоминаем с горячим чувством благодарности. К Зуфару Ярулловичу же почти все его питомцы питают только такое чувство. Об этом говорят отклики. И если принять ученическую благодарность как единицу измерения значимости педагога, то З. Сагитов давно уже занимает почетное место в “высшей лиге“.

Под сводами второй школы родился хоровой ансамбль “Яшьлек“. Состоял он сплошь из одних девочек. Слава Богу, народ дисциплинированный, а то неизвестно чем бы закончился эксперимент их руководителя. А хотел он от “Яшьлека“ добиться ни много ни мало, а многоголосного пения. Тогда некоторые из профессионалов ставили этой идее категоричный диагноз: “абсурд“. Ибо не верили, что такой весьма специфичный “материал“, как татарская песня, может поддаться разбивке на голоса. Но в этом-то, вероятно, и есть разница между просто профессионалом и талантом: последний из невозможного творит чудеса.

Добился-таки своего Зуфар Яруллович. Потом голоса “Яшьлека“ долго радовали серебряным перезвоном зрителей в клубах, Домах культуры, на строительных площадках. Тогда-то и начал сочинять свои песни Зуфар Сагитов. Так появились “Лучи“ (на слова А. Ерикея), “Моя планета“ (на слова Н. Арсланова), “Синие цветы“ (на слова Н. Садыкова). Выступления квартета с исполнением его песен транслировались по республиканскому телевидению, заняли прочное место в репертуаре татарского радио. Всего З. Сагитовым написано более 50 хоровых, инструментальных, вокальных произведений.

Творчество Зуфара Сагитова являет собой удивительный сплав романтики, навеянной строительством КАМАЗа, юношеских грез о любви и лирического коленопреклонения перед красотой родной природы. Если попытаться сказать еще более точно, то, пожалуй, только татарское слово “мон“ в состоянии отразить всю гамму чувств, вмещающихся в его песни.

“Трепещет песня в моей груди“ - это произведение драгоценным камнем украсило корону примы татарской эстрады Альфии Авзаловой. И с ее легкой руки песня перестала быть авторской собственностью З. Сагитова, она стала “народной“. Редкий татарин может признаться, что не слышал ее.

Хотя этот колоссальный успех повторить очень сложно, все же, смею надеяться, на синусоиде своего вдохновения челнинский композитор сможет подняться еще выше.

**Э. МУХАМЕТДИНОВА.**

тиваль программасына кертелә. Алай гына да түгел, фестивальне Зөфәр Яруллович җитәкчелек иткән сәүдә-кулинария училищесының 30 кешелек хоры (конкурста республика күләмендә югары бәяләнгән бердәнбер хор була ул) башкаруында шушы ике җыр белән ачып җибәрәләр. Зөфәр Сәгыйтов фестивальнең лауреаты исеменә лаек була, СССР Композиторлар союзының Алтын медале һәм дипломы белән бүләкләнә.

Үткән ел Җиңү бәйрәме көннәрендә Мәңгелек ут янында барган тантаналарда "Энергетик" мәдәният сараеның ветераннар хоры "Мәңгелек ут" җырын биш көн буе җырлап торды. Җыр "Төзүче" стадионындагы бәйрәмдә кабатланмас тавышлы җырчы, бөтенроссия конкурслары лауреаты Рәфыйк Сабиров башкаруында яңгырады. "Җырның танылуы һәм гомерле булуы аның башкаручысына да бәйле. "День Победы" җыры да Лев Лещенко җырлагач кына бөтен илгә танылды бит. "Мәңгелек ут" җырын Рафыйк кебек башкара алучы юк", — ди Зөфәр Яруллович. Композиторның сүзләрендә хаклык бар: Үткән ел 9 Майда Татарстан радиосы аша җыр ун мәртәбә эфирга чыккан. Күптән түгел Мәскәүдә Җиңүнең 65 еллыгына багышлап конкурс игълан ителүен белеп, Рәфыйк Һадиевич "Мәңгелек ут" җырын конкурска җибәргән. Җюри аның көен һәм башкарылышын ошаткан, күрәсең, русча текстын (Зөфәр Яруллович аны үзе тәрҗемә иткән) соратып алган.

Икенче җырга — "Без тынычлык сакчылары"на килгәндә, анысын Рәфыйк Сабиров быел Бөек Җиңүнең 65 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә башкарачак. Җырны ул беренче тапкыр үткән елның октябрендә композиторның юбилеенда оркестрга кушылып җырлаган.

"Бүген генә "Фронтовик әткәй" диган патриотик рухтагы җырымны тәмамладым — Зөләйха Минһаҗеваның "Әткәй" шигыренә көй яздым", — дип каршылады Зөфәр Яруллович мине берничә көн элек. Пианинода уйнап хәләл җефете Людмила Михайловна (ул да музыка белгече, 1нче музыка мәктәбендә укыта) белән бергәләп җырлап та күрсәттеләр. Күтәренке рухтагы гаҗәеп яңгырашлы бу җыр, һичшиксез, утны-суны кичкән сугел, скрипка, баян, кларнет, тынлы һәм камера оркестрлары өчен дә бик күп әсәрләр язган. Ләкин, ни сәбәпледер, аларны туплап бер җыентык итеп чыгару хәстәрен күрмәгән.

Зөфәр аганың ике музыкаль белеме бар: педагогия институтының музыка һәм Алабуга культура училищесының дирижерлык факультетларын тәмамлаган. Ә музыкаль сәләте — әти-әнисеннән. Дүрт яшеннән тальянда, саратский гармунда уйнаган, Бөек Ватан сугышы елларында Чаллыга күчеп килгәч (тумышы белән Бикләннән ул), үсмер чагында тынлы оркестрда уйнаган. Армиядә инструменталь ансамбль оештырган.

Аның Чаллыда татар җырын дүрт тавышка башкаручы беренче хор оештыруы турында әйтеп үтми ярамас. Чөнки, үзе әйтмешли, бу яктан Зөфәр Яруллович Чаллыда революция ясаган кеше.

Ул елларда үзешчән сәнгать бәйгесендә мәктәп хорлары да үзара ярыша. Вахитов исемендәге мәктәптә музыка укыта башлаган Зөфәр Сәгыйтов шул елны ук ике тавышка җырлаучы хор оештыра һәм коллектив мәктәп хорлары арасында шәһәрдә беренче урынны ала. Икенче елны хор дүрт тавышка җырлый башлый. "Татар җырларын дүрт тавышка хәзер дә бик сирәк җырлыйлар, — дип искәртә музыкант. — Шәһәрдә безнең мәктәп хорына тиңнәр юк иде. Егерме ел беренче булды". Хорда җырлаган укучыларының бик күбе мәктәпне тәмамлагач та үзешчән сәнгатьтә катнаша. Укытучының шәкертләре арасында Галина Казанцева, Лена Борһанова кебек профессиональ җырчылар да бар.

Зөфәр Ярулловичның кызы Лира да консерватория тәмамлап, тормышын җыр-музыка белән бәйләгән. Ул — Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге татар дәүләт фольклор ансамбле артисты — җырчы, скрипкачы.

Үткән ел 80 яшен тутырган Зөфәр ага Сәгыйтовка, үзе әйтмешли, бүген дә покой юк: җырлар, музыкаль әсәрләр яза ул. Ләкин беркайчан да акчага иҗат итмәгән (бу аның өчен ят нәрсә), күбрәк язарга тырышканы юк. Бер булсын — бәрәкәтле булсын, ди. Аннары шунысын да искәртә: композитор халыкка ярап түгел, аны алга әйдәп, чорны узыбрак иҗат итәргә тиеш.

**Кушымта №2**

е, 7 апрель, 2010 ел. №78-79 (3492-3493) Шәһри ЧАЛЛЫ shahrichalli.narod.ru

# Җырлы гомер

**Хәрби авиатор [redacted] шофер, механик, балта остасы, эретеп ябыштыручы, мич чыгаручы, рәссам, тегүче, сәгать төзәтүче, музыка уен кораллары көйләүче, ясаучы, хәтта электр сабаны ясап, 12 ел инде бәрәңге бакчасын шуның белән сөрүче кем дисезме? Милләттәшебез Зөфәр Сәгыйтов. Югарыда саналган һөнәрләре аның "егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз" дигән хак сүзне раслау буларак кына китерелде. Зөфәр абый шәһәрдәшләребезгә иң элек музыка укытучысы, сәхнә ветераны, композитор буларак таныш.**



Илгизә ЛОТФУЛЛИНА

Моннан төгәл егерме биш ел элек, Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан бөтенсоюз патриотик җырлар фестиваль-конкурсы игълан ителгәч, Зөфәр Яруллович "Мәңгелек ут" (Р.Хисамиев сүзләре) һәм "Без тынычлык сакчылары" (Н.Дәүли сүзләре) дигән җырларын язып, конкурска җибәрә. Һәм, Ходайның рәхмәте, җырларның икесе дә жюри

гыш ветераннарына зур бүләк булачак.

Урта һәм өлкән буын кешеләре арасында күпкырлы талант иясе Зөфәр Сәгыйтовның "Тибрәнә җыр күңелдә" җырын белмәүче юктыр: Зөфәр аганың визиткасы кебек ул. Нәкъ менә җырларының гомерлелеге билгели дә инде композиторның осталыгын. Чөнки шәп җырлар гына буыннан-буынга күчеп җырлана бит.

Зөфәр Яруллович җырлар гына

**Кушымта №5**

июнь 02 ел

Ватаным Татарстан

## ҖЫРЛЫ – МОҢЛЫ, ҺӨНӘРЛЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ





Кәдим ага Шәйхетдинов Балтач районы Янгул авылында яши. 76 яше белән барса да, үзенең остаханәсендә агачтан һәм калайдан төрле әйберләр иҗат итә. Аның өендә дә үзе эшләгән затлы мебель тора. Кешеләрнең йомышын үтәп, чүмеч, комган, соскы, кирәк-яраклар ясый. Сез аны үзенең ишек алдында, коелары янында күрәсез.

Музыкант, композитор Зөфәр Сәгыйтов озак еллар Чаллы шәһәре балаларына музыка белеме укыткан педагог: Вахитов исемендәге һәм 5 нче музыка мәктәбендә бу эшне 45 ел башкарган. Чаллы халкы аны атаклы хор дирижеры буларак та белә. Җиңүнең 40 еллыгына багышлап оештырылган Бөтенсоюз конкурсы лауреаты: алтын медаль һәм СССР Композиторлар берлеге дипломы белән бүләкләнгән. Хатыны Люда да музыка укытучысы, Чаллыдагы 13 нче татар сәнгать мәктәбенең теория бүлеге мөдире. Кызлары Лира озакламый Казан консерваториясен тәмамлаячак.


Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотолары.

**Кушымта №6**

Зөфәрдускә! Киләчәктә зур уңышлар, бәхет телим – Мидхәт Ш.

июнь 84 е. Соц. Тат.

Замандашыбыз



# КамАЗ төзелеше ударнигы

...л архитектор да, төзүче дә түгел. Әмма ...ң күкрәген «КамАЗ төзелеше ударнигы» ...н билге бизи. КамАЗ төзүчеләргә, яңа ка...салучыларга культура хезмәте күрсәтүдә, ...ләргә музыка тәрбиясе бирүдә тырышып ...әве өчен лаек булган ул бу мактаулы исем-

...өфәр Яруллович байтак еллар буе Чаллы... Вахитов исемендәге урта мәктәптә музы...укытучысы булып эшләде. Аннары музыка ...тәбендә дәресләр алып барды. Хәзер ни...режнев шәһәрендә ТАССР Сәүдә министр...ның урта профессиональ-техник училище...да музыка җитәкчесе ул. Зөфәр Яруллов ...җитәкләгән хор үзешчән сәнгать коллек...ларының республика смотрларында күп төпкыр дипломнар белән бүләкләнде.

Республикабыз җыр һәм музыка сөючеләре Зөфәр Сәгыйтовны һәвәскәр композитор буларак та яхшы беләләр. Аның «Тибрәнә җыр күңелдә», «Туган җирем Чаллы», «Таң җиле» кебек җырларын профессиональ артистлар да яратып башкаралар.

Ул үзенең музыкасы, матур җырлары белән машина ясаучыларны, шәһәр төзүчеләрне хезмәттә яңадан-яңа җиңүләргә рухландыра, аларга дәрт өсти, илһам бирә. Әнә шуңа күрә дә «КамАЗ төзелеше ударнигы» дигән исемне горур йөртә.

Г. ШӘМСЕТДИНОВ.

Рәсемдә: З. Сәгыйтов.

М. Шакирҗанов фотосы.

зешчән биюче, үзешчән җырчы... диләр. Ә менә
чән шагыйрь сүз тезмәсе никтер телгә кермәгән.
лап уйлап карасаң, мәгънә ягыннан да була ал-
ыр ул. Ничек инде, шагыйрь, ягъни шигъри сүз
сы, оста һәм ... үзешчән?! Башлап язучы яки чә-
диаргә буладыр. Ә шагыйрь - камиллек һәм
чән, кап-каршы ук булмаса да, тәңгәл төшенчә-
дә түгел. Композитор, ягъни көй остасы белән дә
й бу. Шуңа күрә редакциябез кунагы Зөфәр
Сәгыйтовны - байтак көйләре Фәхри Насретди-
Әлфия Афзалова, Рәшит Ваһапов, Вәфирә Гыйз-

зәтуллина кебек танылган җырчыларыбыз репертуарына кергән маэстроны - шәһәребезнең үзешчән түгел, ә олкән композиторы, дип игълан итү дөресрәк булыр. Хәтерлисезме, якты моң тулы "Тибрәлә җыр күңелдә", "Язгы кичтә", "Җырларымны тыңлап белерсең" яисә патриотизм, туган илгә мәхәббәт хисләре белән өретелгән "Татарстаным", "Мәңгелек ут яна"... Сугыштан соңгы буыннарның кечкенәдән ишетеп үскән көйләре.

Буыннар зәвыгы... җыр гомере... композитор белән әңгәмәбез шушы мәгънәләрдән башланды.

БЕЗДӘ УТЫРМАДА

# Җырларымнан танып белсеннәр

**Зөфәр абый, бүгенге
зиторларның попу-
ырлары турында ни
дә Сез? Аларга бир-
ягез нинди?**

Популяр сүзе киң
әле сүз бит ул. По-
.ягъни тиз арада
учыларны әсир ит-
алык арасына тара-
әлгергән икән, бу
ı яхшы яктан
үче сыйфаттыр.
арасында җиңел,
шлягерларның артык
улуы гына эчне по-

**Җиңел дигәне аңла-
Сез текст мәгънәсе-
й бизәкләренең яр-
ын күз алдында то-
ыр инде. Ә төче...**
үмәч кенә була бит,
ле. Урыс, чит ил
зиторларына ияреп-
ән инде ул - соңгы
а лирик җырлар
сы астында интим
р күбәйде. Ике ке-
расында гына кала
хисләр ялангачлан-
мме... Берәү алдан-
енчесе ташлап кит-
Ясалма пафос - ши-
дә, көй дә башкару
тык төче яңгырый.
ік кызларның җыр
ны була торган иде:
кулдан кулга
бер-берсеннән
леп язылган интим
ләр туплана. Алар-
ета-журналларда ба-
п та булмый, сәхнә-
ычкырып сөйләү дә
з - чөнки артык
Аларны йомшак
е туташлар үз алла-
елап-мышкылдап
р гына. Соңгы ел-
әнә шундый альбом
ры күбәйде. Мон-
сәрләрнең гадәттә
те юк. Башкаручы
тан куплетка, ун-
рәт, эчен суыра-
кабатлый: "син ми-
лап киттең, ташлап
киттең"... яисә
кире кайт, кайт!..".
җыр ничек дип
тәрбияви төшкә ия
а, бертөрле мәгъ-
нәтиҗәгә китерергә
р ул. Шул чакта гы-
ның гомере, "авыр-
бар. Лирик җыр бит



бөтенләй башка нәрсә - ул якты, оптимистик рухлы моң...

**- Һәр буынның үз модасы, үз моңымы әллә, Зөфәр абый?**

- Җырчы, композитор күңеленең, аларның рухи ихтыяҗының зәвыксызлануы мода да, моң да була алмый... Бу бик кызганыч һәм зарарлы күренеш, чөнки артист үз зәвыгын тамашачыга да күчерә, сеңдерә бит.

Тыңлаучыда чын зәвык тәрбияләүче көйләр - һәр заманның, буынның җыр сәнгате ни дәрәҗәдә икәнлекне алар билгели. Минем кулыма гармун алып уйнаган тәүге көем "Шахта" булды. Үзем уйныйм, үзем елыйм - ник яшь койганымны ул вакытта әле аңламыйм да...

**- Гармунчыга ничә яшь инде?**

- Дүрт. Гармун күрекләре өстеннән ике күз генә күренеп тора. Укый башлагач, тәнәфесләрдә уйнап, укучыларны биетә башладым. Җәйләрен пионер лагерена чакыралар.

**- Гармунга, гомумән, музыкага әвәслек кемнән килә соң?**

- Безнең әткәй заманы өчен бик укымышлы кеше

иде, МТСта механик бул
эшләде. Бабам истәл
өйдә кечкенә орган һ
гармун бар иде. Алар
әткәй үзе дә, әнкәй
абыйларым да уйный б
пәләр. Беләләр генә түг
ятатып уйныйлар и
Соңрак, әткәй вакытс
дөнья куйгач, тормышл
тыгызланды. Әле дә хә
ремдә: әнигә ияреп Чап
базарына чыккач, гарму
нар сатыла торган җир
килеп туктаддык. И, б
яшь кенә егет сызды
инде аккордеонда! Әнк
дә, мин дә дөньяны оны
тык: авыз ачып карап к
тык. Бармакларым үзл
реннән-үзләре биешеп т
ра инде.

Әнкәй ничек итсә ит
озакламый өйгә аккорд
он кайтты.

Гармун уен коралы г
на түгел, ул гаилә әгъза
кебек - шатлыкны да, х
рәтне дә уртаклашу
булды. Гармун уйн
абыйларны сугышка оз
тык, әлкәнебез Мирзан
сугыш бетәргә ярты
калгач үлү кайгысын
гармун бүлеште. Икенч
без — Мисбах абый,
гыштан исән-сау кайт
гомере буе мәктәптә м
зыка укытты.

Әнкәйнең "Зинге
тегү машинасы бар иде
ул фабрика заказлар
өйгә дә алып кайта: т
буе солдат гимнастеркал
ры, биштәрләр тегә. Б
дә алмашлыйбыз. Күз
йокы тыгыла, билләр с
лый... Шунда әнкәй кул
на гармун алып бер
дәртле көй уйнап җибәр
арыганнар онытылып к
тә...

Армиядә дә гармун
ташламадым мин. А
самбль оештырып, к
цертларда чыгышлар я
дык. Солдат киемен
салмыйча, Чаплының Вах
тов исемендәге урта м
бенә музыка укытучы
булып эшкә урнашты
Күп тә үтмәде, зур х
оештырып җибәрде
Көндез укытам, кичләр
репетиция, әле шәһәрн
тынлы оркестрында
уйнап йөрим...

**- Ә музыка, көйлә
язуга кайчан керештегез?**

- Хор оештырдык, ди
әйтәм бит әле. Күмәкл
җырлауга гына түгел, ә
дүрт тавышка башкарыр
өйрәтәм - ә моңа барыр
дай кулай әсәрләр аз. К
барса, сүзе килми, сү
шәп икән - көе бик гади.

(Дәвамы 3 биттә).

№109 4 август 2004



*Бәйрәмнәребез*

# Яшьлек елларын искә төшереп...

**Чаллыбызның үзенә генә хас традицияләре байтак. Һәр елны июльнең соңгы җомгасында уза торган төп чаллылылар бәйрәме дә шундыйлардан. ГЭС бистәсенең Үзәк урамы ел саен бу көнне бик күп шәһәрдәшләребезне җыя. Алар арасында КамАЗ һәм шәһәр төзелгәнче калабызның текстиль фабрикасында, элеваторда эшләгән кешеләр, мәдәният-сәнгать үсешенә нигез салган сәнгатькәрләр бар. Кама буендагы шәһәр төзелә башлагач төп чаллылылар үзләренең фатирларына элеккеге СССРның төрле почмакларыннан килгән төзүчеләрне сыендырганнар. Кыскасы, төп чаллылылар — Татарстанның икенче зур шәһәренә әйләнгән Чаллы тарихын язучылар алар. Менә шул ягы белән кадерле безгә бу бәйрәм. Халык арасында да, җитәкчеләр арасында да аның дәрәҗәсе елдан-ел арта. Төп чаллылыларны бәйрәм белән котларга быел да мәртәбәле кунаклар байтак килгән иде.**







Хатирәләр... Үзәк урамдагы һәр бакчада ул елларда сирень чәчәкләре үскән. Шушы матур чәчәкләргә, аның хуш исенә хозурланып, композитор Ринат Гобәйдуллин "Чаллы сиреньнәре" дигән җыр язган. Бу җыр төп чаллылыларның гимнына әйләнде. Авторның үзе башкаруындагы әлеге җыр бәйрәмгә килүчеләрне ел саен яшьлекләренә кайтара.

Калабыз халкының нигезен тәшкил иткән шәһәрдәшләребезне котларга хакимият башлыгы Илдар Халиков та килгән иде. "Мондый матур бәйрәм беркайда да юк. Бәйрәм белән сезне, төп чаллылылар! Илебезнең барлык халкы кебек сез дә тормышның төрле этапларын үттегез. Сугышларга балаларыгызны, туганнарыгызны озаттыгыз, кайгылы хатлар алдыгыз, Бөек Җиңү бәйрәмен билгеләп үттегез. КамАЗ, шәһәр төзелешендә катнаштыгыз. Рәхмәт сезгә! Бу – тарихи урын. Шушы территориядәге дебаркадер аша шәһәре-

кебек горурланырлык шәхесләр күп. Сәламәтлек сезгә, бу бәйрәм елдан-ел күбрәк кеше җыйсын, югалмасын иде", – диде ул. Илдар Шәфкатович шәһәр тормышында актив катнашкан 4 төп чаллылыга рәхмәт хаты һәм акчалата бүләк тапшырды.

Бүләккә лаек шәхесләр күп калабызда. Тиздән үзенең 100 еллыгын билгеләп үтүче 2 нче гимназиядә укып һәм шул мәктәптә озак еллар балаларга тирән белем биргән Анна Солтанова, Фәймә Зәйнуллина, Роза Андреева, Зөфәр Сәгыйтов, Мәдинә Камалетдинова, Халидә Шамматова кебек олы җанлы, фидакарь мөгаллимнәргә дә җылы сүзләр әйтеп, бүләкләр тапшырдылар. Аларның элеккеге укучысы, данлыклы табиб Фаяз Газизов үзенең рәхмәтен җиткерде. Чын укытучы өчен моннан да зур бүләк юктыр ул, мөгаен. Үзләренең туган көннәрен билгеләп үтүче Әлфия Латыйпова, Миргарифан Шәмсетдинов, Нури Мингалимов, 50 ел бергә яшәгән Халидә һәм Имам

нең бүләкләре тапшырылды.

Бәйрәм кунакларына чаллылыларның якташлык җәмгыяте җитәкчесе, "КГЭС"ның капиталь төзелеш идарәсе башлыгы А.Петров, "КГЭС" ААҖ генераль директоры А.Евдокимов, язучы Н.Алешков изге теләкләрен һәм рәхмәтләрен җиткерделәр. Гөлшат Мостафина, Илсөяр Зарипова, Мостафа Нигъмәтҗанов җыр-биюләрен бүләк иттеләр. Ул көнне Үзәк урамда беренче талкыр музыкант Илдар Абдуллин скрипканың моңлы тавышын яңгыратты.

2004 елның 30 июль көнендә Үзәк урамда беренче мәктәпне моннан 50 ел элек тәмамлаган сыйныфташлар очрашты. Бер-берләрен кочакларына алдылар алар. Үткән еллар сагындырган: кайберәүләр очрашу-күрешү шатлыгыннан елмая, икенчеләренең күзләрендә күз яшьләре җемелди. Кабат үзеңне укыткан, акыллы киңәшләре белән ярдәм иткән укытучыларың белән очрашу да сөенеч. Сыйныфташлар хатирәләрен яңартып бик озак утырганнардыр әле.

Гомер шулай уза, берәүләр сыйныфташлары, дуслары, туганнары белән очрашып, шатлыклы мизгелләр кичерәләр, ә икенчеләре бөтенләйгә якты дөньядан китә. Быел төп чаллылылар күренекле җәмәгать эшлеклесе Геннадий Филатов, режиссер Мансур Кашапов, футболчы Евгений Мензанов, хезмәт ветераны Зәки Гыйльманов белән мәңгегә хушлаштылар. Ләкин алар онытылмый. Бәйрәмдә аларны бер минутлык тынлык белән искә алдылар.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, күренекле нәфис сүз остасы, Чаллы кызы Гөлзада Рзаева быел да бәйрәмне матур һәм эчтәлекле итеп алып барды. Үзәк урамда җыр-бию озак яңгырады. Якташлар киләсе елда да шунда очрашырга сүз куеп таралыштылар.

**З.ФОАТОВА.**
**Автор фотоларында**


күпәр көй-моңнарда
не бирер тылсым бар...
MANNI

**Кушымта №17**

Январь 71 г.
Тат. Яшьл.

# ЯК, ҖЫРГА КҮЧӘ ТОРГАН ЯК...

Рафис ХИСАМИЕВ сүзләре,

Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы.




## ӘЙТМИМ ӘЛЕ...

Әйдә чыгыйк әле болыннарга,
Ал чәчәкләр өзеп йөрерсең.
Яратаммы сине, әйтмим әле —
Күзләремә карап белерсең.

Әйдә барыйк әле урманнарга,
Аланнарны ямьгә күмәрсең.
Минем күңелдә дә урман шавы —
Күзләремә карап белерсең.

Әйдә чыгыйк әле Зәй буена,
Ярсу дулкыннарны күрерсең.
Сулардан да көчле дулкынланам —
Күзләремә карап белерсең.




### ЧАЛЛЫДА ҖЫР ЯҢГЫРЫЙ

Тик сине, тик сине,
тик сине, туган як,
Күңелемдә һәрвакыт
сакладым...

Бу — Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров җырлый. Чаллы ягы — чыннан да, аның туган ягы. Ул туып үскән Яңа Бүләк авылы моннан берничә генә чакрым ераклыкта.

Илһам Шакиров туган ягына әлек тә бик еш кайтып, концертлар куеп китә торган иде. Чаллыда зур төзелеш башлангач, ул кайтуын тагын да ешайтты. Удар төзелештә кешеләр һаман иштә, аларның культура хезмәтенә ихтыяҗлары да арта бара.

«Идел» инструменталь ансамбле шәһәрнең «Чулпан» кинотеатры, Культура йорты залларында 7 тапкыр «Татар җырлары кичәсе» үткәрде. Җидесендә дә зал шыгрым тулы булды.

Илһамның «аягы җиңел» икән. Аның концертлары тәмамлануга, төзелеш эшчеләре янына Татарстанның җыр һәм бию ансамбле килеп төште.

### СӘНГАТЬ ДУСЛАРЫ АРТА


Салкын, төн уртасы булуга карамастан, Чаллы юллары кайнап тора. Удар төзелешкә материаллар ташучы күптөрле йөк машиналары арасында Чаллы халык театрының автобусы да бара. Менә ул «Камгэс» төзүчеләр поселогында туктала. Машинадан берничә кеше төшеп кала. Автобус ЗЯБ поселогына юнәлә, элеватор тавына менеп китә, автозавод төзүчеләр тулай торагына килеп җитә. Ниһаять, кешеләрне таратып бетереп, Культура йортына килеп туктала. Бу — Чаллы халык театрының чираттагы спектакль белән чыгып, авыл хезмәткәрләренә культура хезмәте күрсәтеп кайтуы.

Бүген театр алдында торган яңа бурычларны

Кушымта №18,19

## Планетам минем

Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы.
Нури АРСЛАНО[В] сүзләр[е]




Тын галәм, серле караңгы,
Йолдызлар уйный;
Янып тора алтын кояш,
Ай нидер уйлый.
Җир зәңгәр шар булып,
Балкый нурга тулып,
Йөзә зур кораблар...
Җырлый космонавтлар.

КУШЫМТА:

Әй, зәңгәр илем,
Иң матур җирем.
Планетам, Планетам,
Планетам минем.
Совет кораблары оча
Гел югарыга,
Ай, Венера, Марсларга,
Каз юлларына.
Тавыштан да җитез
Омтылабыз бит без,
Бездә нык канатлар,
Җырлый космонавтлар.

КУШЫМТА:

Җирдә туып, җирдә үс[еп]
Без җир уллары.
Балкый яңа дөньяларны
Серле нурлары.
Булсалар да алар
Матур Планеталар,
Туган җирен мактар
Батыр космонавтлар.

КУШЫМТА.

## Татарстаным

Зөфәр СӘГЫЙТОВ көе,
Рафис ХИСАМИЕВ шигыре



Ишетәлә синең үткәнеңнән
Яшь кызларның чуплы чыңнары.
Йөзләреңдә Тукай елмаюы,
Күңелеңдә — Сәйдәш моңнары.


Кушымта:
*Халкым рухы балкый байрагыңда,*
*Кояш балкый якты күгеңдә.*
*Татарстан, сөюемнең сиңа*
*Иң кайнарын саклыйм күңелдә.*

Яшелләнә болын, урманнарың,
Дулкынлана игеш кырларың.
Муллануралар нуры таңнарыңда,
Йөрәгеңдә Җәлил җырлары.


Кушымта.

Атларның да кыңгыраулар белән
Яңа чорга чабып кергәне,
Синең белән, мәгърур Татарстан,
Каршылыйбыз яңа иртәне.

Кушымта.



Июнь 66е.




## Синсез

*„Тапшырылмаган хатлар“ пьесасыннан*

ЗӨФӘР СӘГЫЙТОВ

*музыкасы.*

Сагынып көтәм сине җаным,
Көтәм сине, кайт инде, ярым,
Синсез миңа бик-бик күңелсез,
Бик күңелсез миңа, күңелсез.
Синсез миңа — шатлык юк.
Яшәү дә юк миңа синсез.

**Авыл хәбәрчеләре язалар.**

Январь 71е
тат. Яшьл.

# ...ИК, ҖЫРГА КҮЧӘ ТО...

Рафис **ХИСАМИЕВ** сүзләре,

Зөфәр **СӘГЫЙТОВ** музыкасы.


Яңа җыр

## ӘЙТМИМ ӘЛЕ...

Әйдә чыгыйк әле болыннарга,
Ал чәчәкләр өзеп йөрерсең.
Ятаммы сине, әйтмим әле —
Күзләремә карап белерсең

Әйдә барыйк әле урманнарга,
Аланнарны ямьгә күмәрсең.
Минем күңелдә дә урман шавы —
Күзләремә карап белерсең.


Әйдә чыгыйк әле Зәй буена,
Ярсу дулкыннарны күрерсең.
Сулардан да көчле дулкынланам —
Күзләремә карап белерсең.



**Кушымта №22,23**

## ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ

З. СӘГЫЙТОВ музыкасы һәм сүзләре




Таң йолдызына охшатып,
Сөям сине, гүзәлем;
Сине күрми түзә алмыйм,
Өзгәләнә үзәгем.
«Тиздән Чулпанга очам»,—
дип,
Йолдызларны күзлисең,
«Миннән башка очып
китмә»,—

Ди күнелем, сизмисең.
Икебез дә бергә очыйк,
Мин йөрим шуны уйлап,
Таң йолдызында йөрербез
Гөлле бакчабыз буйлап.
Бик сагынсак, туган җирне,
Урманнарны, суларны
Сабан туена кайтырбыз,
Шатландырып дусларны.

Заказ 604

ТАСС Министрла[р]

1 май 65 е.

## ҖИЛЛӘР ИСӘ

Хәсән ТУФАН сүзләре,

Илдус ЯКУБОВ музыкасы.

Тәрәзәмне ачып куйдым,
Килсәнә, җил, керсәнә:
Кадерлемнең хәлләреннән
Берәр хәбәр бирсәнә!


Җитә кичләр, җиләс җилләр
Исәләр дә исәләр.
Читенмени: керсәләр дә,
Исән әле, дисәләр.

И җиләс җил, кил әле, кил!
Безгә керә кит әле.
Бармы җаны, юкмы җаны?
Шуны хәбәр ит әле.

Кичке җилләр сер сөйлиләр
Миңа түгел, гөлләргә...
Синнән аерым көннәремдә
Мин сүз кушыйм кемнәргә?




**Кушымта №24,25**




## НУРЛАР

Әхмәт Ерикәй сүзләре,
Зөфәр Сәгыйтов музыкасы.

Нур чишмәләреннән нурлар алып
Сукмакларга сибәр идем мин,
Сукмакларны түгел, бөтен илне
Саф нурларга күмәр идем мин.

Тапсам әгәр бәхет хәзинәсен,
Шатландырыр идем һәркемне,
Эзләнүгә бирәм, хезмәтемә
Бар көчемне, барлык дәртемне.


Эзлим, эзлим, табармын дип эзлим,
Нур чишмәсен, бәхет диңгезен,
Дөньядагы барлык матурлыкка
Мин күмәргә телим җир йөзен.


Министрлар Советы янындагы Матбугат идарәсенең Яр Чаллы типографиясе ТАССР.
[...]ская типография Управления по печати при Совете Министров ТАССР.
Газета «Знамя коммунизма» дан тәрҗемә итеп басыла.


май 66-

# ТИБРӘНӘ ҖЫР КҮҢЕЛДӘ

Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы, Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА сүзләре.




1) Язын сыерчыклар кайтып,
Оясын тапса;
Бакчаларда алмагачлар
Шау чәчәк атса;
Кояш көлсә,
ай елмайса
Илем күгендә,—
Тибрәнә җыр дулкыннары
Минем күңелдә.

2) Бәхетле елмаеп ана
Баласын кочса;
Тыныч күктә ак юл сызып
Самолет очса;
Дуслар гөрләшеп утырса
Табын түрендә,—
Тибрәнә җыр дулкыннары
Минем күңелдә.

3) Шауласа бодай кырлары
Бөртеккә тулып;
Чакырса ерак офыклар
Яңа юл булып;
Үсеп чыкса зур бер кала
Туган җиремдә,—
Тибрәнә җыр дулкыннары
Минем күңелдә.

# Кушымта №26

Фев өвел

# Әдәби почм

Е. Гаврилов.

## АЙДАН ХӘБӘР

«Луна-9» космос аша
Урак-чүкеч төшкән илдән,
Пар чиләкле Зөһрә кызга
Сәлам алып килде Җирдән,
Җир йолдызы —илчебезне
Кабул иткән айда үзен,
Пар чиләген иңгә салып,
Хәбәр иткән әйтер сүзен:

«Кичәгедән бүген яхшы,
Киләчәгем якты бүгеннән,
Чынбарлыклар колач җәя
Килеп чыгып хыял күгеннән.
Җибәрегез батырларның
Гагариннар кебекләрен,
Көтеп калам
Җирегезнең
Космонавт егетләрен».

## Чәчәк ата илебез!

З. Сәгыйтов музыкасы

М. Кашапов сүзләре.

(«Тапшырылмаган хатлар» постановкасыннан)




Җимердек без коллык богауларын,
Азат сулыш алды халкыбыз.
Зур дәрт белән янып канатланып
Якты киләчәккә атлыйбыз.

Кушымта:
Партия алгы сафта,
Безнең илебез сакта, Илебез безнең сакта.
Якты тормыш төзибез,
Чәчәк ата илебез.

Чыныктык без сугыш кырларында
Җиңеп чыктык дошман яуларын.
Мәрмәр таштан бөек һәйкәл салдык
Үлмәс итеп җиңү даннарын.

Кушымта:

Азатлык сөюче совет халкы
Җирдә тигез тормыш төзечәк.
Планетада балкыр шатлык таңы,
Коммунизм — безнең киләчәк!


Кушымта:

# Чаллы юллары

апрель 70 г.

Нурулла ГАПТУЛЛИН
сүзләре

Зөфәр СӘГЫЙТОВ
музыкасы.




Яшьлек серен саклый торган
Яшел нарат урманы,
Араларны якынайткан
Иркен Чаллы юллары
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.
Кама тугайлыкларында
Үткән сабан туйлары,
Шунда күңелгә эз салып
Яңгыраган җырлары.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.

Күрсәтергә гүзәл көчең
Зур җиңүләр аркылы
Көрәш мәйданына чыккан
Яңа Кама батыры.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.
Кама буе, Чаллы юлы
Илтә туган ягыма.
Шунда яшьлек хыялларым,
Шунда сөйгән ярым да.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.


---

двустворчатую, хотя не могли сказать, почему.
К концу недели, прошедшей в раздумьях, снова захожу к … увидел сидящего за ним незнакомца. Оказалось, на вакантное место уже другого приняли.

А. ЛЕПЕШКИН.

*В номере 165 нашей газеты был объявлен конкурс на лучшую мелодию песни о Набережных Челнах. Победителем конкурса признан преподаватель музыки школы № 2 З. Сагитов. Музыку его песни „Мои Челны" на слова Л. Волкова (см. газету за 17 октября 1970 г.) мы сегодня публикуем.*

# МОИ ЧЕЛНЫ




Верны девушки наши и парни,
Увлеченный народ молодой,
Что подымут свой город на Каме,
Над любимою нашей рекой.

Ветеранами автозавода
Станут в будущем нас называть.
Хорошей город наш, год от года,
Чтобы в песнях тебя воспевать.


**Кушымта №29,30**

Декабрь 1965 ел

# ...ИФӘСЕ

## ЙӨРӘК ҖЫРЫ

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙ сүзләре,
ЗӨФӘР СӘГЫЙТОВ музыкасы.




Күк күзләрең сыман зәңгәрләнеп,
Алсу иренең төсле таң ата;
Йөзең кебек матур булган өчен
Җәйге таңны күңелем ярата.

Керфек сирпеп елмаюларыңны
Күргән саен хәйран калам мин;
Матурлыкны таңга син бирдеңме,
Таңны һәр көн көтеп алам мин.

Безгә якты язмыш биргән өчен
Көн дә рәхмәт әйтәм җиремә;
Басуларны син бизәдеңме әллә,
Бигрәк матур булып күренә...

МАТУРЛЫГЫН ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕН

апрель 70 е.

# Чаллы юллары

Нурулла ГАПТУЛЛИН сүзләре
Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы.




Яшьлек серен саклый торган
Яшел нарат урманы,
Араларны якынайткан
Иркен Чаллы юллары
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.
Кама тугайлыкларында
Үткән сабан туйлары,
Шунда күңелгә эз салып
Яңгыраган җырлары.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.


Күрсәтергә гүзәл көчен
Зур җиңүләр аркылы
Көрәш мәйданына чыккан
Яңа Кама батыры.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.
Кама буе, Чаллы юлы
Илтә туган ягыма.
Шунда яшьлек хыялларым,
Шунда сөйгән ярым да.
Чакыра, үзенә тарта,
Йөрәктә дәрт уята.

Июнь 66 ел

Яңа җыр

# ЯЗГЫ ТАҢ

ЗӨФӘР СӘГЫЙТОВ сүзләре.
РИФКАТЬ ГАРИФУЛЛИН музыкасы.



Бик юксынам сине,
Онытмыйм күзләреңне.
Алар таңдай якты,
Көтәм, иркәм кайт инде.

Күктә ай балкыды,
Без аерылган чакта.
Мин кайтырмын, дидең,
Язгы таңнар атканда.

Кушымта:
Кар сулары ташып акканда,
Төнбоеклар чәчәк атса да.
Син кайтмадың, мин көтәм
сине.
Язгы таңнар күптән атса да.

Таң җилләре миңа,
Сөйлиләр синнән сәлам.
Кайтырсың син тиздән,
Ашкынып шуны көтәм.

Шатлык белән балкый,
Минем якты көннәрем.
Кар суыдай ташый
Сине көткән йөрәгем.

Кушымта:
Салкын көзге җилләр
искәндә,
Төнбоеклар чәчәк койганда.
Син кайттың, иркәм алтын
көздә,
Язгы таңнар алып күңелгә

**Кушымта №31,32**

ЯҢА КӨЙ

# Туган җирем Чаллы

Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы, Һаҗәр ГӘРӘЕВА сүзләре.

Кама ярларына кагылып уйный

1- Сөйгәнемнең күзе төсле зәңгәр,
Акчарлаклы шаян дулкыннар...
Кама буе—туган җирем Чаллы
Җанга рәхәт, җанга якыннар.

Кушымта:

Сандугачлар җырын тыңлап үстем
Бөдрә таллы тугайларында
Кама буе—туган җирем Чаллы
Назлыйм сине хыялларымда.

2- Кама буендагы яшь наратлар
Ак томанга таңда төренә,
Кама буе—туган җирем Чаллы
Сөйгән ярдай якын күңелгә.

Кушымта:


3- Күңелемдә туа матур җырлар
Шул якларга аяк басты исәм,
Йөрәк серләремне аңлар булсаң,
Кама ярларына кил иркәм.

Кушымта:

4- Яшьлек хисләремә канат биргән
Табигатьнең сихри бишеге
Кама буе—туган җирем Чаллы
Көйгә салып җырлыйм исемеңне.

Кушымта:

Шаулы, яшьлек, көрләйторган Кама АЗ
Данга бизи туган җиремне
бөек исемне




Март 1971 ел

ЫЙЗЗӘТУЛЛИН

## …ыгач

…РЧА

…мышык» борын суырып йөр…гән, Хәсән картның кишер тү…тәлләрен утаган бер шук малай

— Канатларым көймәсме соң?..

— Юк, юк, көйми...

Өем, менмим инде, Карлыгач апаңны сагынсаң үзең төш, Заһид апаем...

— Оһ-һай-й...

Ә аннан соң ул көлә-көлә кача башлый, мин аны куып китәм.

— Егетләр! Эһей, Карлыгач очты, тотыгыз тот...

— Ие, шул Заһид абыкаем.

— Ха-ха-ха, әйттеңме инде абый дип... Кара әле, Карлыгач, колагыңа гына бер сүз әйтимме?

— Монда кеше юк ла, кычкырып әйт.

— Юк, кычкырып әйтергә ярамый, буранга ияреп еракларга китә ул алайсам.

Мин чемоданны кар өстенә куйдым да тиздән батып тук…


# ХИФӘ

## ТАТАРСТАН МОҢНАРЫ

таңнары

Гамил АФЗАЛ сүзләре

Зөфәр СӘГЫЙТОВ музыкасы.




Дулкынланып тирбәлә җыр:
«...Сандугач кунмас инде;
Ямьле булса да торган җир
Туган җир булмас инде.

Кошлары сайрый тирәктә,
Сыгылып үсә таллары;
Кайда йөрсәм дә йөрәктә
Татарстан таңнары.

Кызара җәйләр кичендә
Алмаларның аллары;
Кайда йөрсәм дә исемдә
Татарстан таңнары.

Басуларда эшләп үсә
Кызларның уңганнары;
Сагындырып искә төшә
Татарстан таңнары.